
**СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183



**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

# КАРАР

2019 елның 30 нче октябре — № 2

"Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегендә Чаллы Башы авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Шахмай авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге башлыгы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чаллы Башы авылында 1 Май урамы буенча 1-51 һәм 2-48 нче йортларда яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 15 ноябрь көнне сәгать 10.00 га Чаллы Башы авылында 1 Май урамы, 27 нче йорт янында уздырырга дип билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чаллы Башы авылында Чаллы урамы буенча 2-38 һәм 1-39 нчы йортларда яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 15 ноябрь көнне сәгать 14.00 га Чаллы Башы авылында Чаллы урамы, 20 нче йорт янында уздырырга дип билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чаллы Башы авылында Мәктәп урамы буенча 1-45 нче йортларында яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын 2019 елның 18 ноябрендә сәгать 10.00 сәгатькә Мәктәп урамы 46 нчы йорт янында билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чаллы Башы авылында Үзәк урам 38 нче йорт Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын Чаллы Башы мәдәният йортында 2019 елның 18 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Халык җыенын үткәрү өчен Чаллы Башы авылы халкы исемлеген бүлеп сайлау тәртибе территориаль бүленеш буенча башкарылырга тиеш.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, 75тән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Шахмай авылында түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?:

- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү););
- юлларны кардан чистарту;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

"РИЗА" "КАРШЫ"

8. Әлеге карарны «Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы И.Г.Гаризов